СОВЕТ ВАХИТОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ВАХИТОВ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

РЕШЕНИЕ | КАРАР

30.07.2018 | д. им. М. Вахитова | № 47-208

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Уставы проекты турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль Законга, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына, Югары Ослан муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Советының 26.04.2013 ел, № 26-143 карары белән расланган Югары Ослан муниципаль районы Вахитов авыл җирлегендә халык алдында тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә таянып,

Югары Ослан муниципаль районы
Вахитов авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге башлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Уставы проектын беренче укылышта кабул итәргә һәм, тәкъдимнәрне, төзәтмәләрне һәм искәрмәләрне исәпкә алып, аны эшләүне дәвам итәргә (1 кушымта).

2. Югары Ослан муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Уставы проекты буенча кергән тәкъдимнәрне кабул итү, исәпкә алу һәм карау буенча эшче төркем төзергә:

– эшче төркем рәисе, Югары Ослан муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге башлыгы М. К. Идиятуллин;

– эшче төркем секретаре, Югары Ослан муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре ГаббасоваР.В.;

Эшче төркем әгъзалары:

- Сафина Ф. Г. Вахитов авыл мәдәният йорты мөдире
- Бәйрәмова Р. Г. 4 нче Ташевка сайлау округы депутаты
-Җәләлетдинов А. Ш. 5 нче номерлы Бакча-Сарай сайлау округы депутаты.

3. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Вахитовов авыл җирлеге Уставы проектына карата гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибен расларга. (2 нче кушымта).

4. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Уставы проекты буенча фикер алышуда гражданнарның катнашу тәртибен расларга. (3 нче кушымта).

5. 2018 елның 16 августында сәгать 10да Вахитов авыл мәдәният йортында Мулланур Вахитов ис. авыл, Үзәк ур., 24 йорт адресы буенча Вахитов авыл җирлеге Уставы проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрергә

6 . Эшче төркемгә Югары Ослан муниципаль районы Вахит авыл җирлегендә яшәүчеләрнең тәкъдимнәрен гомумиләштерергә һәм аларны Югары Ослан муниципаль районы Вахит авыл җирлеге Советына карау өчен кертергә.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, шулай ук Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Югары Ослан муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Советының социаль-мәдәни мәсьәләләр, Законлылык һәм хокук тәртибе буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет Рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Вахитов авыл җирлеге башлыгы М.К. Идиятуллин